**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица
Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани
урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
«25» 02 2026 ел.

КАРАР
№ 28

**Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 2019 елның 21 октябрендә 165 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.11.2025 ел № 432-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 2019 елның 21 октябрендә № 165 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 8 статьяның 9 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә муниципаль районы Советының бюджетын формалаштыру, икътисадый һәм социаль-икътисадый үсешен фаразлау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе

Р.Ш. Хисамиев